**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш торак пунктында
2025 елда үзара салым кертү турында

**15.11.2024** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылында 2025 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында” Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 05 ноябрендәге 7 номерлы карары нигезендә 2024 елның 15 ноябрендә 10.00 сәгатьтә узган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2025 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

1) халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (тримерга ягулык материаллары, триммер һәм аншлаглар буярга буяу сатып алу)

2) Саклаубаш торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау

3) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, чокыр-чакыр ремонты)

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина